Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Башлыгының «Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Шәмбалыкчы авыл җирлегенең генераль планы проекты буенча ачык тыңлаулар билгеләү турында " 2022 елның 6 декабрендәге 94 номерлы карары

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 16 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы һәм 46 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советының 2018 елның 24 августындагы 175 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (иҗтимагый фикер алышуларны) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә таянып, карар бирәм :

1.Гавами тыңлауларына түбәндәгеләрне чыгарырга

Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Шәмбалыкчы авыл җирлегенең генераль планы проекты;

2.Шәмбалыкчы авыл җирлегенең генераль планының проекты буенча халык алдында тыңлаулар билгеләргә һәм гавами тыңлауларда катнашучыларның җыелышларын уздырырга.

2023 елның 14 гыйнварында 10.00 сәгатьтә Ябалак авылында (Ябалак авылы, Х. Такташ урамы, 28 йорт,авыл мәдәният йорты);

2023 елның 14 гыйнвар көнне 10.30 сәгатьтә Шәмбалыкчы авылында (Шәмбалыкчы авылы, Г. Тукай йорты, 15 йорт,авыл клубы);

2023 елның 14 гыйнварында 11.30 сәгатьтә Түбән Биябаш авылында (Түбән Биябаш авылы, Г. Тукай урамы, 20 йорт,авл клубы);

2023 елның 14 гыйнварында Урта Биябаш авылында 12.00 сәгатьтә (Урта Биябаш авылы, Островский ур., 42 нче йорт,авыл клубы) .

3. Шәмбалыкчы авыл җирлегенең генераль планы проекты буенча ачык тыңлауларны оештыруны һәм үткәрүне Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының «Бакырчы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Генераль планы, Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының «Шәмбалыкчы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Генераль планы проектларын әзерләү комиссиясенә (алга таба – оештыру комитеты)йөкләргә.

4. Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Советының 2014 елның 24 августындагы 175 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасының Апас муниципаль районы » муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә гавами тыңлаулар уздырырга.

5.Шәмбалыкчы авыл җирлегенең генераль планы проекты буенча экспозицияне 2022 елның 8 декабреннән 2023 елның 14 гыйнварына кадәр оештырырга һәм эш көннәрендә 8.00 сәгатьтән 18.00 сәгатькә кадәр, шимбә көнне 8.00 сәгатьтән 12.00 сәгатькә кадәр Шәмбалыкчы авыл җирлегенең башкарма комитеты бинасында, Ябалак авылы, Х.Такташ урамы, 28 йорт адресы буенча экспозициягә бару вакытын билгеләргә.

6.Шәмбалыкчы авыл җирлегенең генераль планы проектын Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының рәсми сайтында (http://apastovo.tatarstan.ru/rus/apastovo1.htm) урнаштырырга.

7.Оештыру комитетына экспозиция эшләү чорында килүчеләр өчен консультацияләр оештырырга.

8. Оештыру комитетына 2022 елның 8 декабреннән 2023 елның 13 гыйнварына кадәр гавами тыңлауларда каралырга тиешле проектка кагылышлы тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кабул итергә.

1) гавами тыңлауларда катнашучыларның җыелышын яисә җыелышларын уздыру барышында язма яисә телдән рәвештә;

2) гавами тыңлауларның оештыру комитеты адресына язма рәвештә (җирлекнең apas.org@tatar.ru электрон почтасы һәм 422350 , Татарстан Республикасы, Апас районы, Апас штп., Советская ур., 2 йорт почта адресы буенча);

3) проект экспозициясенә килүчеләрне исәпкә алу юлы белән.

9. Муниципаль хокукый актларны, башка рәсми мәгълүматны рәсми бастырып чыгару өчен муниципаль берәмлек уставында билгеләнгән тәртиптә гавами тыңлаулар турында хәбәрнамә бастырып чыгарырга.

Район башлыгы
А.Г. Җиһаншин